ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАМАЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
СТАРОКАРАМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

*423982, Р.Т. Муслюмовский район, с.Старые Карамалы, ул.Кооперативная 115а,*
Skarm.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-54-25*
ИНН 1629001113, КПП 162901001, ОГРН 1021605557907, ОКАТО 92242870000

---

**К А Р А Р № 2**

Иске Карамалы авылы «_20_» _декабрь_ 2018 ел

**"Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә 2019 елда үзара салым акчасы хисабына башкарылучы төзекләндерү буенча чаралар исемлеге һәм бер тапкыр түләү (үзара салым) җыюны оештыру турында»**

2004 ел, 24 март, № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2017 елның 20 ноябрендәге 196 номерлы карары белән, 2018 елның 18 ноябрендә узган «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге территориясендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында" карарына нигезләнеп, 2019 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә бер тапкыр түләү (үзара салым) акчаларын үз вакытында җыю максатыннан

**к а р а р б и р ә м:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә 2019 елга бер тапкыр түләү (үзара салым) күләмен 18 яшькә җиткән, нигездә шушы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, «Иске Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге референдумында тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә расларга".

2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, I, II төркем инвалидлар, ӘДР хәрби хәрәкәтләрендә катнашучылар, нурланыш алган яисә нурланыш авыруы, башка авырулар кичергән гражданнар, Чернобыль һәлакәте аркасында инвалидлык алган кешеләр өчен үзара салым күләмен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә.

3. Бер тапкыр түләү срогын 2019 елның 1 мартына кадәр дип расларга.

4. Авыл җирлеге Башкарма комитетына үзара салым акчаларын җыюны катгый
әлеге Карар нигезендә оештырырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

5. Үзара салым акчасы хисабына башкарылачак төзекләндерү буенча чаралар исемлеген расларга (1нче Кушымта).

6. Авыл җирлеге Башкарма комитетына үзара салым акчаларын катгый әлеге исемлек буенча чыгымнар өчен кулланырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

7. Әлеге Карарны Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/amik.htm.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Каримов

Мөслим муниципаль районы
Иске Карамалы авыл җирлеге
Советы Башлыгының
«24» декабрь, 2018 ел
Карарына
1нче кушымта

**Иске Карамалы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы хисабына башкарылучы төзекләндерү буенча чаралар исемлеге**

1. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
2. Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру;
3. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру;
4. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
5. Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү;
6. Каты коммуналь калдыкларын җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
7. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
8. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге;
9. Гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иректе үтеп керүен дә тәэмин итеп, халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру;
10. Җирлекнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;
11. Хуҗасыз хайваннарны тоту(аулау) һәм карап тоту(асрау) буенча чараларны гамәлгә ашыру.